Түбән Өскебаш авыл Советы

КАРАР

27 сентябрь 2022 ел №4

“Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Красная Гора авылы җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 17.11.2021 елда №1 карарына үзгәрешләр кертү турында Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Красная Гора авылында гражданнар җыелышы җыю турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Түбән Өскебаш авыл Советы

карар бирә:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Красная Гора авылы җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 17.11.2021 елда №1 карарына үзгәрешләр кертү турында Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Красная Гора авылында гражданнар җыелышын 08 октябрь 9.00 сәгатькә билгеләргә. Җыелышны түбәндәге адрес буенча үткәрергә: ТР Кукмара районы Красная Гора авылы, Дружба урамы, 64 йорт(авыл клубы)

2. Җыелышта түбәндәге сорауны карарга:

“Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Красная Гора авылы җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 17.11.2021 елда №1 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

-3нче абзац 2 пунктны түбәндәгечә бeлдерергә:

“-Красная Гора авылындагы чишмәне ремонтлау, төзекләндерү, карап тоту; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;”

«РИЗА» «КАРШЫ»

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән карарны бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

Авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов